**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЮГАРЫ ЯХШЫЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423765, Югары Яхшый авылы,
Яна урам,18 нче йорт.
Тел.885552 3-44-45.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АКТАНЫШСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ**
**РАЙОН ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЕРХНЕЯХШЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО**
**ПОСЕЛЕНИЯ**

423765, с. Верхнее Яхшеево,
ул. Новая, дом 18.
Тел. 885552 3-44-45.
E-mail Diliya.Mirzaeva@tatar.ru

---

**КАРАР** **ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«11» декабрь 2025 ел № 24

Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы "Югары Яхшый авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлаулары үткәрү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1, 24 һәм 28 статьяларына, 2003 елның 6 октябрендәге "Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль законга һәм Актаныш муниципаль районының Югары Яхшый авыл җирлеге Уставына туры китереп, Актаныш муниципаль районы Югары Яхшый авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының "Югары Яхшый авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге буенча җир куллану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча җәмәгать тыңлауларын 2025 елның 26 декабренә билгеләргә.
2. Җәмәгать тыңлаулар үткәрү урыны итеп:
   - Тәкмәк авылында, Югары Яхшый авылы, Җиңү ур., 59 йорт адресы буенча урнашкан Югары Яхшый авыл мәдәният йорты бинасы, үткәрү вакыты 10:00;
   - Түбән Яхшый авылында, Түбән Яхшый авылы, Г.Тукай урамы, 47 йорт адресы буенча урнашкан Түбән Яхшый авыл клубы бинасы, үткәрү вакыты 12:00;
   - Табанлы Күл авылында, Табанлы Күл авылы, Гагарин урамы, 55 йорт адресы буенча урнашкан Табанлы Күл авыл клубы бинасы, үткәрү вакыты 14:00;
   - Югары Яхшый авылында, Югары Яхшый авылы, Җиңү ур., 59 йорт адресы буенча урнашкан Югары Яхшый авыл мәдәният йорты бинасы, үткәр вакыты 16:00.
3. Җәмәгать тыңлауларында каралачак мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр һәм фикерләр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Югары Яхшый авылы, Яңа урам, 18 нче йорт.
4. Бу карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат такталарында, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында: http:/aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча "Авыл җирлеге" бүлегендә бастырырга.
5. Бу карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Югары Яхшый авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Әхәтов И. Х.